ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.11.2021 д. им. М. Вахитова № 40

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Ташевка авылында гражданнар җыенын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июленнән Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

Карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең Ташевка авылында 5 декабрь көнне гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Югары Ослан муниципаль районы Ташевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- су җыю колонкаларын һәм янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:

« ӘЙЕ» «ЮК»:

3. Халык җыенын Ташевка авылы, Рабочая урамы, 27 йорт кибет янында 11-00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф. Р. Кәримов